**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләттәшләр эшләре буенча координация советы составына үзгәрешләр кертү турында

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләттәшләр эшләре буенча координация советы төзү турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-703 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 3 ноябрендәге ПУ-717 номерлы, 2012 елның 6 сентябрендәге ПУ-745 номерлы, 2013 елның 6 ноябрендәге ПУ-1083 номерлы, 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1015 номерлы, 2016 елның 23 гыйнварындагы ПУ-27 номерлы, 2016 елның 7 декабрендәге ПУ-1085 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2018 елның 2 февралендәге ПУ-132 номерлы, 2018 елның 6 июлендәге ПУ-473 номерлы һәм 2019 елның 8 февралендәге ПУ-88 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләттәшләр эшләре буенча координация советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан Р.И. Вәлиевны, Р.Р. Гыйматдиновны, Г.Р. Нигъмәтуллинаны, Р.А. Шәйхетдиновны чыгарырга;

б) Совет составына кертергә:

Бакиров Газинур Тәлгать улын – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесен;

Низамова Ләйсән Габделхан кызын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгын;

Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улын – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесен;

Хәйруллин Айрат Ринат улын – Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрын;

в) Совет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Р.З. Закировның – «Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча)»;

А.Р. Зариповның – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе (килешү буенча)»;

Р.А. Ратникованың – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Татарстан Республикасы законнарының татар һәм рус телләрендәге текстларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясе рәисе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 31 гыйнвар
№ ПУ-50